**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«12» май 2002 ел № 10

«2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауны гамәлгә ашыру максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 170 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 11, 13 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын расларга (кушымта №1).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Э.Р. Низамиева

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның «12» май 10 номерлы карарына кушымта

# «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасы

2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклау буенча муниципаль программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | РФ Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Заказчы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Програм маның төп максаты | Круглое Поле авыл җирлеге җирләрен саклау һәм алардан рациональ файдалану буенча чараларны тормышка ашыру |
| Программаның билгеләнеше | Круглое Поле авыл җирлеге җирләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2022-2024 еллар |
| Көтелгән нәтиҗәләр | Җирләрне саклау һәм рациональ файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, бозылган җирләрне торгызу, халыкның экологик куркынычсызлыгын һәм аның тормыш сыйфатын күтәрү |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту | Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны тормышка ашыру механизмы | Җир хуҗаларының һәм кулланучыларның җирләрне саклау һәм алардан рациональ файдалану буенча эшчәнлеген координацияләү Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла. Программага кирәк булганда төгәллек кертелә |
| Финанслау чыганагы | Программаны үтәү муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.<br>Муниципаль берәмлек бюджеты хисабына программаны финанслау күләме 3 мең сум тәшкил итә.<br>2022 ел – 1 мең сум.<br>2023 ел – 1 мең сум.<br>2024 ел – 1 мең сум. |

## 1. Муниципаль программаны тормышка ашыруның агымдагы торышы характеристикасы һәм тиешле өлкәсенең төп проблемалары

Җир – әйләнә-тирә мохитнең мөһим өлеше, аны куллану башка табигать объектлары: хайваннар, урманнар, үсемлекләр дөньясы, сулар, файдалы казылмалар һәм җир асты байлыклары һәм аның башка кыйммәтләре белән бәйле. Җирне кулланмыйча һәм сакламыйча башка табигый ресурслардан файдалану мөмкин түгел. Җиргә карата хуҗасызлык кичекмәстән яки якын киләчәктә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерәчәк, җирнең өске катламы – туфрак җимерелүгә, аның химик һәм радиоактив пычрануына гына китереп калмыйча, бөтен табигать комплексы экологик яктан начарланачак.

«2022 - 2024 елларга Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм саклау» муниципаль программасы (алга таба – Программа) җирләрне куллану һәм саклау өчен икътисадны ныгыту максатында җир ресурсларыннан нәтиҗәле һәм рациональ файдалану һәм идарә итү буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итә торган уңай шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Җир фондының зур күләмнәрен төрле максатларда куллану әйләнә-тирә мохит экосистемасының барлык звеноларының табигый бөтенлеген саклау буенча билгеле бер бурычлар йөкли. Табигатьтә барысы да үзара бәйләнгән. Шуңа күрә бер звеноның дөрес эшләвен бозу, урманмы ул, хайваннар дөньясы, җирме, экосистеманың бөтенлеген бозуга китерә.

Җирне рациональ файдаланмау, аңа кулланучы буларак һәм хуҗасыз караш ул башкара торган функцияләрнең бозылуына, табигый үзлекләрнең кимүенә китерә.

Җирләрне саклау җирдән рациональ файдалану булганда гына нәтиҗәле булырга мөмкин.

Круглое Поле авыл җирлегенең тотрыклы социаль-икътисади үсеше һәм анда яшәүчеләрнең экологик имин тормышы хәзерге этапта җирләрне саклау һәм файдалану проблемаларын хәл итү белән тыгыз бәйләнгән. Авыл җирлеге дәрәҗәсендә җирләрне саклау һәм файдалану буенча җирле проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә мөмкин, шуның белән бергә, хәзерге вакытта яшәүче кешеләр генә түгел, киләчәк буын мәнфәгатьләрендә тулы, комплекслы һәм акыллы итеп хәл итәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге территориясендә төрле рөхсәт ителгән файдаланудагы җир кишәрлекләре бар.

Аеруча кыйммәтле җирләр булып авыл хуҗалыгы җирләренә караган авыл хуҗалыгы файдалануындагы җирләр тора.

Җирлек территориясендә көтүлекләр культура-техник торышы буенча, нигездә, чиста. Көтүлекләр шәхси ярдәмче хуҗалыклар тарафыннан файдаланыла.

Көтүлек азыгын барлык кулланучыларны да исәпкә алып, табигый көтүлекләр кимеми. Җирлектәге барлык көтүлекләрдә диярлек яшеллек артыгы белән.

Җирләрнең экологик торышы уртача яхшы, әмма стихияле санкцияләнмәгән чүплекләр әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый һәм экологик хәлне катлауландыра.

## 2. Муниципаль программаны тормышка ашыруның максатлары, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре, сроклары һәм этаплары

Җирлек территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль сәясәтнең төп принциплары булып Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенең законлылыгы һәм ачыклыгы, хисаплылыгы һәм контрольдә булуы, нәтиҗәлелеге тора.

Муниципаль программаның максатлары булып җирләрне һәм туфракларны пычратуны, ярлыландыруны, деградацияләүне, бозуны, юкка чыгаруны һәм җирләргә һәм туфракка башка тискәре йогынтыны булдырмау, шулай ук җирләрне рациональ файдалануны тәэмин итү, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту тора.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- куллану эшчәнлеген оптимальләштерү;
- җирләрдән рациональ файдалану һәм саклау нәтиҗәлелеген күтәрү;
- яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу;
- җирләрне инвентаризацияләү.

Җирләрне инвентаризацияләү җирләрне деградацияләүне, пычратуны, чүпләүне, бозуны, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысын булдырмау, файдаланылмый торган, рациональ кулланылмый торган яисә максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмый торган һәм җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдаланылмый торган җирләрне, җирләрнең башка характеристикаларын ачыклау максатыннан башкарыла.

Әлеге программаны тормышка ашыру җирдән файдалануны тәртипкә салуга, яңа җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертүгә, авыл җирлегенең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга, нәтиҗәдә, икътисадны үстерүгә, җирләрне нәтиҗәле файдалануга һәм саклауга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә тәэмин ителәчәк:

1) торак пунктларны төзекләндерү;
2) җирләрнең сыйфат характеристикаларын яхшырту;
3) җирләрдән нәтиҗәле файдалану.

Программаны тормышка ашыру срогы 2022-2024 еллар.

## 3. Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауның һәм файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар планлаштырылган.

| N | Чаралар исеме | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (сум) | Башкаручы | Үтәү вакыты | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Авыл хуҗалыгы файдалануындагы җирләрне агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре үсүдән һәм зарарлы организмнардан саклау буенча чаралар үткәрү | Җирле бюджет:<br>2022 ел – 500 сум.<br>2023 ел – 500 сум.<br>2024 ел – 500 сум. | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2022-2024 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2. | Деградациягә, пычрануга, чүпләнүгә дучар булган, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысында бозылган җирләрне яхшыртуны һәм торгызуны тәэмин итү | Җирле бюджет:<br>2022 ел – 500 сум.<br>2023 ел – 500 сум.<br>2024 ел – 500 сум. | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2022-2024 | Башкарма комитет җитәкчесе |